**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап (решения/ответы)**
**2021-2022 учебный год**
**9 класс**

**I. Гыйбарәләрнең татарча эквивалентларын языгыз / Напишите татарский вариант речевых реплик** (10 баллов. *За каждый правильный вариант по 1 баллу* ).

1) Что мне делать? – Нишлим?/ Нәрсә эшлим?; 2) Так нельзя – Болай ярамый; 3) Неужели? – Шулаймыни? /Булмас! ; 4) Браво! – Афәрин! 5) Подождите немного – Бераз көтегез; 6) Что случилось? – Нәрсә булды? 7) Совершенно верно! – Бик дөрес! 8) Будьте внимательны! – Игътибарлы булыгыз!; 9) Конечно! – Әлбәттә!/Бер сүзсез! 10) Превосходно! – Күз явын алырлык!/ Искиткеч!

***II.* Хәрефләрне дөрес тәртиптә урнаштырып, сүзләрне табыгыз. Алардан мәкаль төзегез. /** Составьте из букв слова. Найдите пословицу**.** (10 баллов. *За нахождение слов 5 баллов, засоставлени е пословицы 5 баллов).*

*РЫККЫ БСӘМИРЕШ РБЕ УКМ ЫЛЫШЫ ААГДНН*

*Бер укымышлы кырык наданга бирешмәс.*

***III.* Сүзтезмәләрнең һәр элементын антонимнары белән алыштырып языгыз. /** Замените каждый элемент словосочетаний антонимами (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 1 баллу*).

Төньякка бару – көньяктан кайту;
кышын табу – җәен югалту,
кичәгедән соң оныту – иртәгәгә кадәр искә төшерү;
акка пычрату – карадан чистарту;
соң кайту – иртә китү;
сиңа җавап бирү – аннан(миннән) сорау;
урамга китү – өйдән килү;
кичен белү – иртән белмәү;
болытлы көн – аяз төн;
җылы керү – суык чыгу.

**IV. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм 3) төрен билгеләгез** / Сделайте 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему и 3) определите тип предложения (15 баллов. За каждое задание по 5 баллов).


Үз җыры бар башкаручылар азая бау сәбәпле, эстрадада үзгәрешләр сизелә. (ВМ)

1) Үз <u>җыры</u> бар (2) <u>башкаручылар</u> азая бару сәбәпле, (3) эстрадада <u>үзгәрешләр</u> сизелә (ВМ).

Үз – аергыч
Җыры – ия
1) Бу – ситететик иярчен аергыч җөмлә)
Бар – хәбәр
Башкаручылар – ия
Азая бару – хәбәр
Сәбәпле – бәйләүче чара, хәбәр слставында карала
2)( бу – синтетик иярчен сәбәп җөмлә)
Эстрадада – кыек тәмамлык

Үзгәрешләр – ия
Сизелә - хәбәр.

2.




3. Бу – бер-бер артлы ияргүче күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. .

**V. Тексттан гарәп-фарсы алынма тамырлы сүзләрне язып алыгыз.** / Выпишите из текста слова с арабо-персидскими корнями. (10 баллов, по 1 баллу за каждый правильный пример)

Өянкенең дә бала чагы, үткәне була. Кәүсәсенә еллар бәҗрасы өстәлгән саен, аның **хәтере** дә байый баруын кешеләр беләләр микән? Ул, яшел кабыклы нәзек тал булып, **дөньяга** беренче тапкыр күзен ачканда, авыл урамыннан, тузан туздырып, җигүле атларда бүтән **гасыр** кешеләре уза иде әле. Аның иң беренче теләге **бакча** читәне аша үрелеп карау булды, **әмма** буе җитмәде. Кыска буйлы тал-тирәк ихата эчен күзәтә башлады. Янәшәдә генә – сиртмәле кое. Арырак – салам түбәле өй. Кое сиртмәсе, шыгырдап, бер төшә, бер күтәрелә. Янәшәдә генә салкын җир дымын, **шифалы** су **тәмен** тою тал-чыбыкка **рәхәтлек** бирә. Аның тизрәк үсәсе **һәм** ак **болытларга** ябалдашы белән орынасы килә. (М. Галиев)

**VI. Татар телендә килешләрнең вазифысы турында языгыз. Мисаллар белән аңлатыгыз.** / Напишите о функциях падежей в татарском языке. Приведите примеры. (15 баллов. За описание каждого падежа по 2 *балла. +3 балла за описание грамматической категории*).

Татар телендә 6 килеш бар. Килешләрдә исемнәр, алмашлыклар һәм исемләшкән башка сүз төркемнәре төрләнә ала. Килеш категориясенең грамматик мәгънәсе төрле килештә килгән сүзләрнең җөмләдәге синтаксик функцияләре нигезендә формалаша.

Баш килеш җөмләнең барлык кисәкләре дә булып килә ала. Баш килештәге сүз эшдәш сүз, ымлык вазифасын да үти.

Иялек килеше предметның иясен, хуҗасын белдерә. Сүзләр җөмләдә, күбесенчә, аергыч һәм тәмамлык булалар.

Юнәлеш килеше эшнең вакытка яки урынга юнәлүен белдерә. Сүзләр җөмләдә тәмамлык булалар.

Чыгыш килеше эшнең чыгыш ноктасын белдерә. Җөмләдә тәмамлык яки хәл, хәбәр була.

Төшем килеше туры объектны белдерә, һәм бу килештәге сүзләр җөмләдә тәмамлык булалар.

Урын-вакыт килеше урынны, вакытны белдерә. Җөмләдә хәл, хәбәр вазифысын үти.

**VII. Түбәндәге морфологик таләпләргә туры килгән сүзләрдән торган җөмлә төзеп языгыз.** / Напишите предложение, слова в которого соответствуют следующим морфологическим требованиям. (10 баллов. Каждое слово оценивается 1 *баллом*).

1 нче сүз – исем сүз төркеме, баш килештә, берлек санда;
2 нче сүз **–** исемләшкән сыйфат фигыль, үткән заманда **,** урын-вакыт килешендә;
3 нче сүз – исем сүз төркеме, баш килештә, берлек санда;
4 нче сүз **–** бәйлек сүз, 3 зат берлектәге тартым белән төрләнгән, юнәлеш килешендә;
5 нче сүз – рәвеш, күләм-чама рәвеше.
6 нчы сүз – кисәкчә,
7 нче сүз – сыйфат, асыл сыйфат, гади дәрәҗәдә.
8 нче сүз – билгесезлек алмашлыгы.
9 нчы сүз – исем сүз төркеме, ясалма, баш килештә, берлек санда;
10 нчы сүз –хикәя фигыль, билгеле үткән заманда, өченче затта, берлек санда, барлыкта.

**Айсылу җырлаганда бүлмә эчендә җиңелчә генә моңсу бер тынлык урнашты.**

**VIII. «Кояш - чыгышта, кош - очышта, кеше юмартлыкта матур. (Мөсәгыйт Хәбибуллин» канатлы сүзен сез ничек аңлыйсыз? Шушы гыйбарәдә әйтелгән фикергә таянып, 80 сүздән артмаган инша языгыз. /«Солце - на заре, птица - во взлёте, человек в доброте красивы» (Мусагит Хабибуллин)** Напишите, как вы понимаете данный афоризм? Опираясь на это выражение, напишите сочинение (не более из 80 слов) (20 баллов).

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар, | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | **ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |